
# Сыйныф сәгате




**КАЗАН ШӘҺӘРЕ СОВЕТ РАЙОНЫ
АБДУЛЛА АЛИШ ИСЕМЕНДӘГЕ 20 НЧЕ ГИМНАЗИЯ
БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФ УКЫТУЧЫСЫ
МИНИМУЛЛИНА А.Х. ТӨЗЕДЕ**











# БУ РӘСЕМНӘР НИНДИ ӘКИЯТЛӘРДӘН? АЛАРНЫ КЕМ ЯЗГАН?

- Абдулла Алиш  1908 нче елның 15 нче сентябрендә хәзерге Спас районы Көек авылында туган . Бабасы Нурулла мулла булган , ә әтисе Габделбари хуҗалык эшләре белән шөгельләнгән –иген иккән , умарта караган. Әнисе Газизә укымышлы булган , шигырь һәм бәетләр чыгарган. 8 яшьтә Абдулланы әтисе үзләреннән 15 км ераклыктагы авылга мәдрәсәгә биргән. Аннан педагогия техникумы каршындагы мәктәпне тәмамлый.
  1927нче елда Казанга килә , җир төзү техникумында укый. Шунда алган һөнәре буенча эшли. 1937нче елдан Бөек Ватан сугышы башланганчы “ Пионер каләме” ( “Ялкын”) журналы редакциясендә, радиокомитетта эшли. Педагогия институтында укый. Иң күп язган еллары була бу. Алишны балаларның сөекле язучысы иткән әсәрләр-  әкиятләр. 20 дән артык әкият яза. Аларны “Нечкәбил” , “Әкиятләр” , “Ана әкиятләре” исемнәре белән бастырып чыгара.













- Сугыш башлангач , 1941 нче елда фронтка китә , разведчик була. Чолганышта калып, фашистлар кулына әсир төшә. Берлин төрмәсендә Муса Җәлил белән очраша.
- 1944 нче елның 12 нче августында фашистлар Алишны үтерәләр. Ләкин әдипнең гомерен үлем чикләми. Абдулла Алиш , көрәштәше Җәлил кебек үк, туган халкы белән бергә киләчәккә горур атлап бара.

- . “Сыерчык белән чыпчык” кайсы әкият геройлары? *(“ Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык”)*
- 2. “Бу нинди боерык ? Нәрсә ул койрык ? “ бу җөмләләр кайсы әкияттән? *(“ Койрыклар”)*
- 3.”Кайгырма , туганкай, йомшак Куянкай, кызыңның аягын бик тиз төзәтеп була.” *(“Куян кызы”)*
- 4. “ Серең эчендә торса , йортың тыныч булыр, җимерелмәслек нык булыр.” *(“Сертотмас үрдәк”)*



# “Каз белән Аккош” әкиятен искә төшерик.

**..... үзенең бәбкәсен төрлечә сыйлап караган: тәмле-тәмле балыклар, яшел бакалар, татлы кыскычлар тотып китерә икән. Баласы, үзе зур булса да, кулына кашык тотып ашамаган, әнисенең ашатуын көткән. Ашау аңа бик зур эш булган. Ашарга-эчәргә тотынса, ул тәмам йөдәп беткән.**
**Ә дуга муен — ..... баласы кыстатып та тормый, кашыкны үзе тотып, азыкны кат кат чәйни, тәмле итеп ашый икән. Вакытында йоклый, вакытында һавага чыга, уйный, шуңа күрә алма кебек кызарып, матур булып үсә икән.**



“Чукмар белән Тукмар” әкиятендә А.Алиш безне нинди булмаска өйрәтә?









“Куян кызы” әкиятнен персонажларын санап бирегез.




**2001нче елда туган авылы Көектә Абдулла Алишка һәйкәл салынды. Көектә , Казанның Балалар иҗаты үзәгендә,55 мәктәптә аңа багышланган музейлар эшли. 1990 нчы елда ул 1нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән үлгәннән соң бүләкләнде. Менә кем булган ул - Абдулла Алиш.**